ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.04.2026 с.Старое Дрожжаное №139

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 07 февралендәге 66 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **6 пунктта:**

беренче абзацта «матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга» сүзләрен «матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкны эвакуацияләүне планлаштыруны, әзерләүне, гамәлгә ашыруны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауны оештыру;»;

2) **9 пунктта:**

беренче абзацта «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халык өчен хәвеф-хәтәрләр барлыкка килү» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләр» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «оборона һәм» сүзләрен «оборона, җиһазландыру һәм кирәкле көчләрне әзерләү» сүзләренә алмаштырырга;

3) **10 пунктта:**

беренче абзацта «хәрби конфликтларда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәлнең гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «хәрби конфликтларда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

4) **11 пунктта:**

беренче абзацта «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар нәтиҗәсендә килеп чыккан» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «, сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) **14 пунктта:**

беренче абзацта «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар нәтиҗәсендә килеп чыккан» сүзләренә алмаштырырга;

6) **17 пунктның** беренче абзацында «хәрби конфликтларда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «сугыш вакытында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда мобилизация чорында барлыкка килә торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш һәм ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җитәкче Р.И. Мөхәммәтҗанов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1061672000689 ИНН 1617003116